КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 октябрь г.Казань № 858

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү процессын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче; 2020 ел, 12 июнь, 485 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче, 2022 ел, 18 гыйнвар, 21 нче, 2022 ел, 06 декабрь, 1291 нче; 2023 ел, 18 февраль, 154 нче, 2024 ел, 02 июль, 495 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Юллама алу өчен шифаханә-курорт дәвалануына мохтаҗ граждан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яшәү урыны буенча территориаль органына (алга таба - социаль яклау территориаль органы) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гариза бирә, түбәндәге документларны теркәп:

шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен 070/у номерлы форма буенча белешмәhttps://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=369436&dst=100712;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 нче карары белән расланган Нигезләмәгә кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацында һәм 2 пунктындагы бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документлар – күрсәтелгән керемнәр булганда;

күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, әлеге күчемсез мөлкәт объектларына хокук бирә торган документларның күчермәләре (алга таба - КМБДР).

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча тикшерү идарәләренә вазыйфаларга күчерү тәртибендә билгеләгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре, шулай махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) ук югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарның гаиләләре әгъзалары (алга таба - махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар), әлеге Тәртипне куллану максатларында аларга күрсәтелгән гражданнарның хатыны (ире) һәм ата-анасы керә, шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итүгә беренче чираттагы хокукны раслау өчен өстәмә рәвештә тапшыралар:

чит илнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән, аларны махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына йә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслый торган документлар күчермәләре һәм аларның нотариаль расланган тәрҗемәләре;

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы (алга таба - Федераль закон) нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның аның шәхси белешмәләрен социаль яклауның территориаль органына тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалыгы.

Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасы белән интегүче граждан, законнар нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган очракта, мондый авыру барлыгы турында өстәмә белешмә бирә.

Граждан гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклый торган документ күрсәтә.

Документларны һәм белешмәләрне граждан тиешле оешмаларда турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә ала.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм территориаль социаль яклау органы белгече тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль яклау территориаль органына түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә кәгазь чыганакларда почта аша җибәрелә;

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы) шәхси кабинеттан файдаланып, электрон рәвештә;

«Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) шәхси кабинеттан файдаланып, электрон рәвештә.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны электрон рәвештә яисә аларның электрон образлары мондый документларны булдырырга һәм имзаларга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп, имзаланырга тиеш.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша җибәргәндә, электрон документлар формасында гариза һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 211 һәм 212 статьялары (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә имзаланырга (таныкланырга) тиеш.

Гариза бирүче гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә куелу язмасын стандарт дәрәҗәсеннән ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк»;

2.2 нче пунктның 2.2.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.2.1. Ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада гражданны юллама

алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә вәкаләтле оешмалардан пенсия билгеләү турында;

гражданның уртача айлык керемен санаганда исәпкә алына торган керемнәр турында (Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән керемнәрдән тыш);

күчемсез мөлкәт булу турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төре булу турында;

торак урынны яшәү өчен яраксыз дип билгеләнгән тәртиптә тану турында;

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) турында;

хезмәткәрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булмавы турында;

аларны махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына йә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләре турында;

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның махсус хәрби операциядә катнашу (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары өчен), я аның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булуы (вафаты) (махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) факты турында.

Шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек алып барганнан соң, шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр ала.

Граждан үз инициативасы белән территориаль социаль яклау органына, гариза белән бергә, бу пунктның икенче – тугызынчы абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

2.2 пунктның 2.2.4 пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктының бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырган һәм шифаханә-курорт дәвалануын беренче чиратта тәэмин итү хокукын раслаган 2.1 пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән затлар арасыннан гражданнар шифаханә-курорт дәвалануын беренче чиратта тәэмин итүгә хокукы булмаган гражданнар алдына куела.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин